**КАРАР**
**Микулино авыл җирлеге Советы**
**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**

Микулино авылы № 163 «22» 04. 2020ел.

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Советының кайбер карарларын гамәлдән чыгару турында

2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон һәм муниципаль хокукый актларны муниципаль хезмәт турындагы гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан

Микулино авыл җирлеге Советы карар итә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге советының түбәндәге карарларын гамәлдән чыгарырга:

- 2017 елның 16 октябреннән 69 нче номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Микулино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленең бердәм башкарма орган буларак, коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә катнашу яисә аларның коллегиаль органнары составына керү өчен бушлай нигездә катнашу (эш бирүче) рөхсәтен алу тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары;

- 2019 елның 05 апреленнән 131 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Микулино авыл җирлеге Советының 2017 елның 16 октябреннән 69 номерлы карары белән расаланган «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Микулино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленең бердәм башкарма орган буларак (сәяси партиядән тыш) коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашу яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керү өчен бушлай рөхсәт алу тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында» карары.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмати-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис И.А.Такиулин